| СОВЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16.12.2019 г.Зеленодольск № 452

Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында субсидияләр бирү тәртибе турында

Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл иткәндә барлыкка килә торган җирле үзидарә органнарының вәкаләтләрен үтәгәндә, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.3 статьясы нигезендә, «Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесенең Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субсидияләр бирү тәртибе турында мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында субсидияләр бирү тәртибен расларга. (кушымтада бирелә)

2. Әлеге карар нигезләмәләре, бюджетларны төзегәндә, раслаганда һәм үтәгәндә, 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына бюджетлардан башлап, барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы

муниципаль берәмлекләре порталы (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) составындагы Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы урынбасары** **Э.Р.Кадникова**

Зеленодольск муниципаль районы
Советының 2019 елның 16 декабрендәге
номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында субсидияләр бирү тәртибе

1. Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субсидияләр чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча барлыкка килгәндә (алга таба - субсидияләр, җирлекләр) түбәндәге очракларда бирелә:

җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәүгә җирлекнең субсидияләр бирүгә ихтыяҗы булу;

Зеленодольск муниципаль районы бюджетының өстәмә керемнәре исәбеннән, шулай ук Зеленодольск муниципаль районы бюджетында экономия булганда, агымдагы финанс елы башына һәм (яисә) ассигнованиеләрне яңадан бүлү исәбенә Зеленодольск муниципаль районы бюджеты счетындагы акчаларның калган өлеше;

законда каралган башка очракларда.

2. Субсидияләр Зеленодольск муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль район бюджеты турындагы карарында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

3. Җирлекләр бюджетына субсидияләр бүлү, Зеленодольск муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль район бюджеты турындагы карары белән раслана.

4. Субсидияләр бирүнең максаты һәм шартлары, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты һәм җирлекнең Башкарма комитеты арасында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты раслаган форма буенча, төзелгән килешүләр белән билгеләнә.

5. Килешүдә түбәндәге төп нигезләмәләр булырга тиеш:

а) субсидиянең максатчан билгеләнеше;

б) субсидия бирү һәм тоту шартлары;

в) субсидияләр бирүгә каралган бюджет ассигнованиеләре күләме;

г) субсидияне күчерү графигы;

д) субсидия бирү һәм тоту өчен билгеләнгән шартларның үтәлешен тикшереп тору тәртибе;

е) финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидияләр булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап бирү сроклары һәм тәртибе;

ж) килешүнең шартларын бозган өчен якларның җаваплылыгы.

6. Килешү проектын әзерләү Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

7. Килешү проекты Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитеты тарафыннан җирлекнең Башкарма комитетына җибәрелә.

8. Килешү Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе һәм җирлек Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан имзалана.

9. Субсидия алу өчен ,җирлекнең Башкарма комитеты килешү белән билгеләнгән срокларда, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына түбәндәге документларны тапшыра:

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты раслаган форма буенча субсидияләр бирүгә гариза;

Килешү белән билгеләнгән башка документлар.

10. Җирлек бюджетына бирелә торган субсидия күләме килешү белән билгеләнгән формула буенча билгеләнә.

11. Субсидияләр җирлекләр бюджетына Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең җирле бюджетлар үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен килешүдә билгеләнгән срокларда ачылган территориаль органнары счетларына күчерелә.

12. Субсидияләр бирү шартларын бозган очракта тиешле акчалар, Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә, Зеленодольск муниципаль районы бюджеты керемена күчерелергә тиеш.

13. Субсидияләр биргән елдан соң килүче елның 1 гыйнварына файдаланылмаган субсидияләрнең калган өлеше , Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы бюджеты керемена кайтарылырга тиеш.

14. Субсидияләрдән максатчан файдалануны закон нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты һәм муниципаль финанс контроле органнары контрольдә тота.